БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 5 » май 2018 ел № 141

**Өстенлекле инвестиция проектларын карау һәм аларга ярдәм итү буенча комиссия турында**

Балтач муниципаль районы икътисадына инвестиция ресурсларын җәлеп итү буенча эшнең нәтиҗәлелеген арттыру, уңай инвестиция климаты булдыру, "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы өстенлекле инвестиция проектларын карау һәм аларга ярдәм итү буенча комиссия төзергә һәм 1 нче кушымта нигезендә аның составын расларга.
2. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р. И. Шакиров